
# Галимҗанов Әбүбәкер Галимҗан улы
# (1912 – 1991)





**«Янып калсын гомрең, маяк булып
Үзеңнән соң килгән буынга.
Утта булган балчык кире купмас,
Эштә булган тимер тутыкмас.
Эш күрсәткән ирне ил онытмас,
Каберенә эзне суытмас»**

**Муса Җәлил**

Минем бабам, сугыш һәм хезмәт ветераны Галимҗанов Әбүбәкер Галимҗан улы, 1912нче елның 31нче ноябрендә Кариле авылында туган. Башлангыч белемне Кариле мәктәбендә ала. Бала чактан авылда крестьян хезмәтендә чыныгып үсә. 1932-1934 елларда эшче-крестьян Кызыл Армиясе сафларында хезмәт итә.

Әбүбәкер Галимҗанов армиягә кадәр үк колхозга кайткан иң беренче техник җайланмаларда, машиналарда эшли. Хәрби хезмәтен тутыргач та туган авылына кайтып, техника тирәсендә эшли. 1941нче елның башында аны Биектау районының Усад авылындагы механизаторлар хәзерләү курсларына укырга җибәрәләр. Бөек Ватан сугышы башлангач та авыл өчен алыштыргысыз кадр буларак аңа бронь бирәләр. Тик язмыш бүтәнчә хөкем итә – 1942нче елда кайдандыр авылына кайтып барганда, поездан төшереп, аны берничә иптәше белән фронтка озаталар.

Ул иң авырлардан берсе булган каһәрле Волхов фронтына эләгә, укчы полкта наводчик булып мондагы авыр, озакка сузылган позицион сугышларда катнаша. Соңыннан Балтик буе республикаларын, Польшаны азат итүдә, Германиянең башкаласы Берлинны алуда катнаша. Сугыш юлларында күрсәткән батырлыклары өчен Әбүбәкер Галимҗанов Беренче дәрәҗә Ватан сугышы, Икенче һәм өченче дәрәҗә Сугышчан Дан орденнары, “Батырлык өчен” һәм башка бик күп сугышчан медальләр белән бүләкләнә. Тыныч хезмәткә кайткач Әбүбәкер Галимҗанов Балтач МТСында трактор бригадасы бригадиры, Тимирязев исемендәге колхозда тракторчы булып эшли. 1991 елның октябрь аенда вафат була, Кариле зиратына күмелгән.



# Галимжанов Әбүбәкер Галимжан улының орден – медальләре



# Бабайларыбыз батырлыгына дан!!!



2 һәм 3 дәрәҗә Дан орденнары

# 2 һәм 3 дәрәҗә Дан орденнары









# Беренче дәрәҗә Ватан сугышы ордены









# "Батырлык ечен" медале




XXX
ЗА ОСВОБОЖДЕНИЕ
ВАРШАВЫ
ЗА
ВЗЯТИЕ
БЕРЛИНА

# Юбилей медальләре












1918
1988